| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.10.2017 Казан ш. № 283

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 07 апрелендәге 76 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 07 апрелендәге 76 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясенең хосусый составы үзгәртелгәндә Дәүләт комитеты рәисенең боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт комитетында граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган чорда шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.»;

3.2 пунктында «вакант вазыйфага» сүзләрен «вакант вазыйфаны биләү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкетаны, фотосы белән;»;

3.5 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Дәүләт комитетына Дәүләт комитеты рәисе исеменә тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган рәвештәге анкетаны фотосын теркәп тапшыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.5.1 пунктын өстәргә:

«3.5.1. Шушы Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар, аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Дәүләт комитетының рәсми сайтында игълан урнаштырылган көннән соң 21 көн эчендә, Дәүләт комитетына гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан Дәүләт комитетына шәхсән, почта аша җибәреп яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, эшкә алучының вәкиле аларны карап тикшерүнең вакытын күчерергә хокуклы.»;

3.6 пунктының икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерүгә дучар була.»;

3.7, 3.8 пунктларының көчен югалтуын танырга;

4.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.2. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында кадрлар бүлеге тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

4.4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, Дәүләт комитеты рәисе конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документларны кабул итү тәмамланган көннән соңгы 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча уздырыла, ә

дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта конкурсның икенче этабын уздыру вакыты Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан билгеләнә.

Кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көне калган чордан соңга калмыйча, үзенең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Дәүләт комитетының рәсми сайтында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (граждан хезмәткәрләренең) (алга таба – кандидатлар) исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу буенча документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.»;

4.4.9 пунктындагы «вазыйфага карата» сүзләрен «вазыйфаны биләү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктындагы «вакант вазыйфасына карата» сүзләрен «вакант вазыйфаны биләү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9 Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шушы ук вакыт эчендә «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында урнаштырыла.»;

4.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле җымлә өстәргә:

«Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов